КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 март г.Казань № 166

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүгә, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеген җайга салуга, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслауга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органын билгеләү турында» 2017 ел, 14 ноябрь 867 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүгә, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеген җайга салуга, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслауга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органын билгеләү турында» 2017 ел, 14 ноябрь 867 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 545 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктның икенче абзацына «төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алу турындагы документларны әзерләүгә һәм раслауга,» сүзләреннән соң «төбәк оператор белән килешү эчтәлеген һәм аны төзү тәртибен билгеләүгә,» сүзләрен өстәп үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин